БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_30_» ___04____ 2020 ел № _164_

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында**

«Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура, спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен акчалата түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1258 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура, спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов